**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
РЫБНО-СЛОБОДСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАЛЫК БИСТӘСЕ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

22.12.2015 Балык Бистәсе штп. № 355пи

"2016 -2020 елларга Татарстан
Республикасы Балык Бистәсе
муниципаль районының авыл яшьләре"
муниципаль программасын раслау
турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2014 - 2020 елларга Татарстан Республикасында яшьләр сәясәтен, физик культураны һәм спортны үстерү «дәүләт программасын раслау турында» 2014 елның 7 февралендәге 73 номерлы карарын гамәлгә ашыру максатларында «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Уставы нигезендә КАРАР БИРӘМ:

1. «2016 -2020 елларга Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының авыл яшьләре» муниципаль программасын (алга таба-Программа) расларга.

2. Программаның заказчысы – координаторы итеп «Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының яшьләр сәясәте, спорт һәм туризм бүлеге» муниципаль казна учреждениесе билгеләргә.

3.Балык Бистәсе муниципаль районының Финанс-бюджет палатасына ел саен чираттагы финанс елына Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының бюджетын формалаштырганда, әлеге максатларга Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы бюджетыннан җибәрелә торган акчалар чикләрендә, мөмкинлекләрне исәпкә алып, Программа чараларын тормышка ашыру өчен акча бүлеп бирүне тәкъдим итәргә.

4. Әлеге карарны http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”нда һәм Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында игълан итәргә.

5.Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Җитәкче Р.Х. Хәбибуллина

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе
муниципаль районы Башкарма
комитетының 2015 елның 22 декабрендәге
335 пи номерлы карары белән расланган

**"2016-2020 елларга Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының авыл яшьләре" муниципаль программасы**

**Программа паспорты**

| | |
|---|---|
| Программа исеме | "**2016-2020** елларга Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының авыл яшьләре" муниципаль программасы (алга таба- Программа) |
| Муниципаль заказчы | "Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының яшьләр сәясәте, спорт һәм туризм бүлеге " муниципаль казна учреждениесе |
| Программаны төп эшләүче | "Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының яшьләр сәясәте, спорт һәм туризм бүлеге " муниципаль казна учреждениесе |
| Программаның төп чараларын үтәүчеләр | Татарстан Республикасы муниципаль районының Башкарма комитеты;<br>"Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының яшьләр сәясәте, спорт һәм туризм бүлеге " муниципаль казна учреждениесе;<br>"Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының мәгариф бүлеге" муниципаль казна учреждениесе;<br>"Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының социаль-мәдәни өлкә бүлеге" муниципаль казна учреждениесе;<br>Балык Бистәсе районы "Халыкны эш белән тәэмин итү үзәге" дәүләт казна учреждениесе (килешү буенча);<br>Россия Эчке эшләр министрлыгының Балык Бистәсе районы буенча бүлеге (килешү буенча);<br>«Балык Бистәсе үзәк район хастаханәсе» ДАСУ (килешү буенча);<br>Татарстан Республикасының Балык Бистәсе районы авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсе (килешү буенча);<br>«Балык Бистәсе агротехника техникумы» ДАҺБУ (килешү буенча);<br>"Авыл офыклары" ("Сельские горизонты") газетасы редакциясе (килешү буенча);<br>Балык Бистәсе муниципаль районы составына керүче |

| | |
|---|---|
| | җирлекләрнең башкарма комитетлары (килешү буенча) |
| Программаның максаты | Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы авыл яшьләренең социаль һәм икътисадый активлыгын арттыру өчен шартлар тудыру |
| Программаның бурычлары | 1) авыл яшьләрен мәгълүмат белән тәэмин итү системасын булдыру;<br>2) авыл яшьләренең социаль активлыгын арттыру өчен шартлар тудыру;<br>3) авыл яшьләренең икътисадый активлыгын арттыру өчен шартлар тудыру;<br>4) авыл яшьләренең рухи, физик һәм иҗади үсешенә ярдәм итү.<br>5) авыл җирлегендә яшәүче яшьләрне иҗтимагый, социаль-икътисадый һәм мәдәни тормышка тарту.;<br>6) яшьләр сәясәте өлкәсендә район кадрлар резервын формалаштыру. |
| Программаны тормышка ашыру сроклары | **2016-2020** еллар |
| Программаны тормышка ашырудан көтелгән нәтиҗәләр | Программаны тормышка ашыру нәтиҗәсендә 2020 елга кадәр түбәндәгеләрне арттыру күздә тотыла:<br>авыл яшьләренең барлык консультация төрләре (шәхси, электрон, телефон) белән колачланган чагыштырма санын авыл яшьләренең гомуми санына карата 56,7% ка кадәр;<br>«Татарстан Республикасы Аграр яшьләр берләшмәсе» төбәк иҗтимагый оешмасы эшчәнлегенә җәлеп ителгән 15-30 яшьләрдәге яшьләрнең чагыштырма санын авыл яшьләренең гомуми санына карата 58,6 процентка кадәр;<br>җирле советта авыл яшьләренең өлешен депутатларның гомуми санына карата 12,9% ка кадәр;<br>социаль проектлаштыру буенча белем алган авыл яшьләренең чагыштырма санын авыл яшьләренең гомуми санына карата 24 процентка кадәр;<br>авылны социаль үстерү программаларында катнашучы авыл яшьләренең чагыштырма санын авыл яшьләренең гомуми санына карата 64,5 процентка кадәр;<br>бизнес-планлаштыру нигезләренә өйрәнгән авыл яшьләренең чагыштырма санын авыл яшьләренең гомуми санына карата 28,4 процентка кадәр;<br>интеллектуаль-иҗади чараларга җәлеп ителгән авыл яшьләренең чагыштырма санын авыл яшьләренең гомуми санына карата -95,8 процентка кадәр;<br>физкультура-сәламәтләндерү чараларына җәлеп ителгән авыл яшьләренең чагыштырма санын авыл яшьләренең гомуми санына карата 66,3% ка кадәр;<br>сәламәт яшәү рәвешен формалаштыру программаларында катнашучы авыл яшьләренең чагыштырма санын авыл яшьләренең гомуми санына карата 74,5 процентка кадәр. |
| Программаны тормышка ашыруга контроль | «Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының яшьләр сәясәте, спорт һәм туризм бүлеге» муниципаль казна учреждениесе программа чараларын тормышка ашыруны планлаштыруны, үзара |

<table>
<tr><td></td><td>хезмәттәшлекне, координацияләүне һәм контрольдә тотуны оештыра.</td></tr>
<tr><td>Программаны тормышка ашыру механизмы</td><td>«Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының яшьләр сәясәте, спорт һәм туризм бүлеге» муниципаль казна учреждениесе, район оешмалары, учреждениеләре, службалары белән берлектә, программаның үтәлешен координацияли һәм контрольдә тота, кирәк булганда, программа чараларын ачыклау буенча тәкъдимнәр кертә.</td></tr>
<tr><td>Ресурслар белән тәэмин итү</td><td>Җирле бюджет (агымдагы финанслау), федераль һәм республика бюджеты акчалары.<br>Программаны финанслауның гомуми күләме 3 371,5 мең сум тәшкил итә, шул исәптән җирле бюджет акчалары хисабына-3 371,5 мең сум.
<table>
<tr><th>ел</th><th>Балык Бистәсе муниципаль районы җирле бюджет акчалары (ҖБ)</th></tr>
<tr><td>2016</td><td>627,5</td></tr>
<tr><td>2017</td><td>686,0</td></tr>
<tr><td>2018</td><td>686,0</td></tr>
<tr><td>2019</td><td>686,0</td></tr>
<tr><td>2020</td><td>686,0</td></tr>
<tr><td>Барлыгы:</td><td>3 371,5</td></tr>
</table>
Искәрмә: финанслау күләме фаразланган характерда һәм җирле бюджет мөмкинлекләрен исәпкә алып, ел саен төзәтмәләр кертелергә тиеш.</td></tr>
</table>

# I. ПРОГРАММАНЫ ТОРМЫШКА АШЫРУ СФЕРАСЫНЫҢ ГОМУМИ ХАРАКТЕРИСТИКАСЫ, ШУЛ ИСӘПТӘН ПРОГРАММА ХӘЛ ИТҮГӘ ЮНӘЛДЕРЕЛГӘН ПРОБЛЕМАЛАР

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районында гомуми халык саны 27,9 мең кеше тәшкил итә, мәктәп яшендәге балалар саны 2959 кеше, 18-30 яшьләрдәге район яшьләре – 5800 кеше.

Авыл халкы саны ел саен кими. Бу процессның төп сәбәпләреннән берсе - авыл яшьләренең шәһәргә күчүе. Шәһәргә нигездә 18-35 яшьлек яшьләр китә. Бу халыкның хезмәткә сәләтле һәм белемле өлеше. Бу яшьтә күпләр гаилә кора. Аларга туучы балаларның дүрттән өч өлеше туры килә. Авыл яшьләре арасында, барыннан да элек, эшкә яраклы яштән яшьрәкләр саны кимүгә бәйле тискәре тенденцияләр күзәтелә.

Яшьләр белән эшләүче белгечләр бәяләвенчә, иң кискен проблемаларның берсе – авыл яшьләренең мәшгульлеге проблемасы. Шул ук вакытта мәшгульлек яшьләрне эш белән тәэмин итү генә түгел, ә бәлки аларның ялларын оештыру, социаль активлык, эшкуарлык инициативасын үстерү, район эшчәнлегенә интеграция ясау да. Авыл яшьләре төрле мөмкинлекләр чикле булу сәбәпле, район тормышында да бик сирәк катнаша.

Авыл яшьләренең социаль хәлен тикшерүләр күрсәткәнчә, бүгенге көндә аларның 48,4% ы гына үз тормышыннан тулысынча канәгать. Яшь буын вәкилләренең яртысыннан артыгы (51,7%) төрле дәрәҗәдә канәгатьсезлек кичерә.

Авыл яшьләренең, социаль төркем буларак, тулы мәгънәдә социаль хәле дә юк. Ул барлык проблемалары белән бүгенге заман яшь буынының үсеш дәрәҗәсен чагылдыручы яшь төркемен барлыкка китерә.

Соңгы 15 елда мәгълүмат һәм коммуникацияләр дөньясында авыл яшьләренең активлыгы бик нык үзгәрде. Актив Яшьләрнең игътибарыннан китаплар, радио һәм газеталар кебек мәгълүмати каналлар "китте". Шул ук вакытта авыл мәгълүмат кыры өстәмә, үзенә күрә компенсатор социаль функцияләр башкара:

- психологик, мәдәни, танып-белү, белем бирү, күңел ачу-ял итү, виртуаль, идеологик (дөньяви карашлар).

Авыл яшьләренең мәгълүмати активлыгын үстерүдә төп бурыч-мәгълүмати-аңлату ярдәме күрсәтү.

Һичшиксез, Интернет челтәре-авыл өчен иң перспективалы мәгълүмати-ресурс каналларының берсе. Авыл яшьләренең мәгълүмати активлыгы бу динамик үсүче коммуникатив киңлектә эзлекле рәвештә көчәя. Тик әлегә авыл яшьләре Интернет челтәреннән файдалану интенсивлыгы буенча шәһәр яшьләреннән шактый калыша.

Бүгенге авыл яшьләре арасында проект эшчәнлеген һәм эшкуарлыкны үстерү мөһим бурыч булып тора. Ә бу аларны социаль проектлауга, бизнес-планлаштыруга өйрәтүдән башка мөмкин түгел. Хәзер моны интернет челтәре ярдәмендә дистанцион укыту һәм вебинарлар программаларыннан файдаланып башкарырга мөмкин.

Проект эшчәнлеге инновацион, иҗади эшчәнлек рәтенә керә, чөнки ул чынбарлыкны үзгәртеп коруны күз алдында тота, тиешле технология нигезендә төзелә, аны унификацияләргә, үзләштерергә һәм камилләштерергә мөмкин. Социаль инновацион проектлаштыру яшьләр мохите үсешенең факторы булып тора, шәхес формалашуга, аны социальләштерүгә, аның билгеле бер күнекмәләренә һәм гражданлык җәмгыяте тормышында аеруча тулы канлы катнашуына ярдәм итә.

Социаль проектлаштыру нигезләрен үзләштерүнең актуальлеге, беренчедән, әлеге технологиянең барлык һөнәрләр өчен дә киң куллану өлкәсенә ия булуы белән бәйле. Икенчедән, социаль проектлаштыру логикасын һәм технологиясен белү белгечләргә аналитик, оештыру-идарә һәм башка функцияләрне, бигрәк тә дәүләт яшьләр сәясәте, физик культура һәм спорт өлкәсендә нәтиҗәле гамәлгә ашырырга мөмкинлек бирәчәк. Өченчедән, проект технологияләре белгечнең хезмәт базарында көндәшлеккә сәләтлелеген тәэмин итә – социаль яктан әһәмиятле проект эшләү һәм аны финанслауга гариза рәсмиләштерү-бу

гамәлдәге учреждениеләр һәм оешмалар кысаларында да, аннан тыш та үзенә эш урыны булдыру мөмкинлеге.

Икътисадый кризис шартларында яшьләрне эшкә урнаштыру мәсьәләләре тагын да актуальләшә бара. Килеп туган хәлне аңлап, яшьләр үз потенциалларын тормышка ашыруның барлык яңа ысулларын эзли башлый.

Авыл яшьләре ялларын оештыру өлкәсендә дә кыенлыклар кичерә.

Әлеге факторлар яшьләрнең шәһәргә күчүен, авыл социумыннан читтә эш эзләүне көчәйтә. Тикшеренү күрсәткәнчә, авыл яшьләренең 57,7% ы өчен күчеп китүгә уку теләге , 67% ы өчен - начар хезмәт шартлары, 69,2% ы өчен - түбән хезмәт хакы, 50% ы өчен кызыклы ял булмау мотив булып тора. Шул ук вакытта авыл яшьләренең проблемаларын хәл ителсә, аларның өчтән ике өлеше авылда калыр иде. Бу мәсьәләдә сыйфатлы алга китеш ясалмаса, яшьләр өлкәсендәге күп кенә чаралар һәм инициативалар тулы социаль һәм икътисади нәтиҗәгә ия булмаячак. Югарыда әйтелгәннәр районның авыл яшьләренең тормыш сыйфатын яхшыртуга юнәлдерелгән комплексы чараларның актуальлеген раслый.

Районның төрле өлкәләрдә (мәгариф, сәламәтлек саклау, элемтә, транспорт һ. б.) социаль-икътисади үсеше, авыл җирлекләрендә яшәү рәвешен модернизацияләү һәм эшчәнлекнең перспективалы юнәлешләре нәтиҗәсендә аларның җәлеп итүчәнлеген арттыру, киләчәкләрен нәкъ менә шунда төзергә теләгән авыл яшьләре өчен оптималь мөмкинлекләр булдырырга мөмкинлек бирәчәк.

Авыл яшьләре алдында торган проблемаларны хәл итү максатыннан Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районында «Балык Бистәсе муниципаль районы аграр яшьләр берләшмәсе» иҗтимагый оешмасы төзелде. Ул авыл яшьләренең мәнфәгатьләрен һәм омтылышларын гәүдәләндерә.

## II. ПРОГРАММАНЫҢ ТӨП МАКСАТЫ ҺӘМ БУРЫЧЛАРЫ, ПРОГРАММА ЧАРАЛАРЫ, КӨТЕЛГӘН СОҢГЫ ТАСВИРЛАМАСЫ ҺӘМ АНЫ ГАМӘЛГӘ АШЫРУ СРОКЛАРЫ

Программаның максаты-Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы авыл яшьләренең социаль һәм икътисадый активлыгын арттыру өчен шартлар тудыру.

Әлеге максатка ирешү өчен түбәндәге бурычлар хәл ителергә тиеш:

1) авыл яшьләрен мәгълүмат белән тәэмин итү системасын булдыру авыл яшьләренә массакүләм мәгълүмат чаралары, мәгълүмат-полиграфия продукциясе аша, шулай ук IT-технологияләрне куллану юлы белән махсус җайлаштырылган мәгълүматны җиткерергә мөмкинлек бирәчәк;

2) авыл яшьләренең социаль активлыгын арттыру өчен шартлар тудыру авыл яшьләре мәсьәләләре белән шөгыльләнүче яшьләр оешмаларын булдыруны, авыл яшьләренең иҗтимагый-сәяси активлыгын күтәрүне, авыл яшьләрен социаль проектлауга өйрәтүне һәм яшьләрне авылны социаль үстерү программаларын гамәлгә ашыруга җәлеп итүне күздә тота;

3) авыл яшьләренең икътисадый активлыгын арттыру өчен шартлар тудыру авыл яшьләрен бизнес-планлаштыру нигезләренә өйрәтүне, авыл җирендә яшьләрне эш белән тәэмин итүгә ярдәм итүне һәм яшьләрне авылны икътисадый үстерү программаларын гамәлгә ашыруга җәлеп итүне үз эченә ала;

4) авыл яшьләренең рухи, физик һәм иҗади үсешенә ярдәм итү интеллектуаль-иҗади һәм физкультура-сәламәтләндерү чараларын оештыруны һәм үткәрүне, шулай ук яшүсмерләр һәм яшьләр арасында сәламәт яшәү рәвешен формалаштыруга ярдәм итүне күздә тота;

5) авыл җирлегендә яшәүче яшьләрне иҗтимагый, социаль-икътисадый һәм мәдәни тормышка тарту;

6) яшьләр сәясәте өлкәсендә район кадрлар резервын формалаштыру.

Авыл яшьләре белән эшләү рәвешләрен һәм ысулларын даими камилләштерү зарурилыгы аркасында программаны тормышка ашыру 5 елга исәпләнгән (2016 елдан 2020 елга кадәр) һәм бер этапта гамәлгә ашырыла.

Программаны вакытыннан алда туктату каралмаган.

## III. ПРОГРАММАНЫ ТОРМЫШКА АШЫРУ МЕХАНИЗМЫ

Программаның үтәлешен планлаштыру, үзара хезмәттәшлек итү, координацияләү һәм гомуми контрольне программаның заказчысы-координаторы башкара. Ул ел саен Программаның максатчан күрсәткечләрен һәм чараларына чыгымнарны, аны тормышка ашыру механизмын һәм башкаручыларның составын тәгаенли, чараларны үтәү өчен җаваплы башкаручылардан программа үтәлеше турында мәгълүмат соратып ала.

Программаның төп башкаручысы-«Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының яшьләр сәясәте, спорт һәм туризм бүлеге» МКУ, ул түбәндәге функцияләрне башкара:

-җирле бюджеттан бүлеп бирелә торган финанс средстволарын, бюджеттан тыш чыганакларны исәпкә алып, Программа чараларын финанслауны тәэмин итә;

-билгеләнгән тәртиптә муниципаль район җирлекләрендә авыл яшьләре мәсьәләләре белән шөгыльләнүче яшьләр иҗтимагый оешмалары булдыруга һәм аларга ярдәм итүгә булышлык күрсәтә.

Программаны башкаручылар заказ бирүче-программаның координаторына Программа чараларының үтәлеше турында билгеләнгән форма буенча хисап бирәләр.

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитеты Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре, спорт һәм туризм министрлыгына Программаны үтәү буенча эшләрнең барышы һәм финанс чараларын куллануның нәтиҗәлелеге турында мәгълүмат җибәрә.

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының яшьләр сәясәте, спорт һәм туризм бүлеге «МКУ программасы чараларын тормышка ашыру өчен»:

- чираттагы финанс елына финанс чаралары программасын тормышка ашыруга бүлеп бирелә торган финанс чараларын исәпкә алып, ел саен максатчан индикаторларны, программа чараларын тормышка ашыруга киткән чыгымнарны, программаны тормышка ашыру механизмын һәм аны башкаручыларның составын аныклый;

-квартал саен, хисап чорыннан соң килә торган айның 25 числосына кадәр, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының территориаль үсеш бүлегенә, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының Финанс-бюджет палатасына программаны тормышка ашыру буенча эшләрнең барышы һәм финанс чараларыннан файдалануның нәтиҗәлелеге турында мәгълүмат җибәрә.

## IV. ПРОГРАММАНЫ РЕСУРСЛАР БЕЛӘН ТӘЭМИН ИТҮ

Программа озак вакытка исәпләнгән перспективага ия һәм Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының авыл яшьләрен этаплап колачлауны күздә тота. Программаны тормышка ашыру өчен, мөмкинлекләрдән чыгып, федераль бюджет, Татарстан Республикасы бюджеты һәм җирле бюджет акчалары җәлеп ителә, шулай ук авыл һәм шәһәр җирлекләре һәм бюджеттан тыш чыганаклардан акча җәлеп итү күздә тотыла.

Программаны финанслауның гомуми күләме 3 371,5 мең сум тәшкил итә, шул исәптән җирле бюджет акчалары хисабына-3 371,5 мең сум.

| ЕЛ | Балык Бистәсе муниципаль районы җирле бюджет акчалары (ҖБ) |
|---|---|

| | |
|---|---|
| 2021 | 627,5 |
| 2022 | 686,0 |
| 2023 | 686,0 |
| 2024 | 686,0 |
| 2025 | 686,0 |
| Барлыгы: | 3 371,5 |

Искәрмә: финанслау күләме фаразланган характерда һәм җирле бюджет мөмкинлекләрен исәпкә алып, ел саен төзәтмәләр кертелергә тиеш.

Программа чараларын гамәлгә ашыру өчен чараларны башкаручыларның төп эшчәнлеген финанслауга бүлеп бирелә торган җирле бюджет акчаларыннан файдалану күздә тотыла.

Программаны финанслау күләме фаразланган характерда һәм тиешле елга җирле бюджет проектын формалаштырганда билгеләнгән тәртиптә ел саен анықланырга тиеш.

## V. ПРОГРАММАНЫ ТОРМЫШКА АШЫРУДАН КӨТЕЛГӘН НӘТИҖӘЛӘР

Программа чараларын тормышка ашыру мөмкинлек бирәчәк:

-яшьләр иҗтимагый оешмаларында торучы авыл яшьләре өлешен арттырырга;

-җирле үзидарә органнарында авыл яшьләре вәкилләренең өлешен арттырырга;

- авылны социаль һәм икътисадый үстерү программаларын гамәлгә ашыруда катнашучы авыл яшьләре санын арттырырга;

-авыл яшьләрен социаль проектлаштыру һәм бизнес планлаштыру нигезләренә өйрәтергә;

-югары һөнәри белем алган, авыл җирлегендә эшкә урнашкан авыл яшьләре санын арттырырга.

-авыл җирлегендә интеллектуаль-иҗади чаралар оештырырга.

- авыл яшьләре өчен физкультура-сәламәтләндерү чаралары оештырырга.

- сәламәт яшәү рәвешен формалаштыру программаларында катнашучы авыл яшьләре санын арттырырга.

Социаль проектлауга, бизнес-планлаштыруга өйрәтү авыл яшьләренә грант нигезендә конкурсларда катнашу, үз эшләрен башлау, аз чыгымлы һәм нәтиҗәле программалар һәм проектлар кертү мөмкинлеге бирәчәк.

Программаны тормышка ашыру кысаларында программаны башкаручыларның яшьләр сәясәте өлкәсендә эшләүче конкрет белгечләре, торак, ташламалы кредитлар, белем алу турында махсус мәгълүматка ия булган хәлдә, команда эше, социаль проектлау, бизнес-планлаштыру технологияләреннән файдаланып, Программа бурычларын үтәүгә ярдәм итәчәкләр, эшнең адреслыгын, авылда төрле социаль, икътисадый программаларны тормышка ашыруны тәэмин итәчәкләр.

Программа чараларын уңышлы үтәү түбәндәгеләрне тәэмин итәргә мөмкинлек бирәчәк:

-авыл яшьләренең республиканың социаль-икътисадый үсеше белән кызыксынуы һәм аның бу процесста катнашырга әзерлеге;

-авыл җирлегендә уңай демографик тенденцияләрне үстерү һәм ныгыту;

-авыл җирлегендә социаль киеренкелек дәрәҗәсен киметү;

-авыл яшьләренең шәһәргә күчүен киметү;

- халыкның дәүләт структураларына ышаныч дәрәҗәсен күтәрү;

-авыл яшьләренең тормыш сыйфатын яхшырту.

"2016-2020 елларга Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының авыл яшьләре" муниципаль программасына кушымта

**2016-2020 ЕЛЛАРГА ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАЛЫК БИСТӘСЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ АВЫЛ ЯШЬЛӘРЕ МУНИЦИПАЛЬ ПРОГРАММАСЫН ГАМӘЛГӘ АШЫРУ БУЕНЧА ЧАРАЛАР ПЛАНЫ**

**1.Авылны социаль үстерү программаларын тормышка ашыру**

Авыл яшьләренең икътисадый активлыгын арттыру өчен шартлар тудыру авыл яшьләрен бизнес-планлаштыру нигезләренә өйрәтүне, авыл җирендә яшьләрне эш белән тәэмин итүгә ярдәм итүне һәм яшьләрне авылны икътисадый үстерү программаларын гамәлгә ашыруга җәлеп итүне үз эченә ала

| № п\п | Чаралар исемлеге | Уздыру сроклары | Җаваплы башкаручылар | Ахыргы нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары, үлчәү берәмлеге | Финанс чыгымнары (агымдагы финанслау), мең сум һәм индикатор күрсәткечләре | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | 2016 ел | 2017 ел | 2018 ел | 2019 ел | 2020 ел |
| 1 | Авыл җирлегендә эшчәнлек алып баручы яшь эшкуарларны әзерләү программаларын гамәлгә кертү | 2016-2020 еллар | ЯССТБ МКУ, АХ һәм АТИ (килешү буенча), “ХМҮ” ДКУ (килешү буенча) | Бизнес-планлаштыру нигезләренә өйрәнгән авыл яшьләренең чагыштырма саны авыл яшьләренең гомуми санына карата, % | -<br>20,4% | -<br>22,4% | -<br>24,4% | -<br>26,4% | -<br>28,4% |
| 2. | Авыл җирлегендә алдынгы фермер хуҗалыклары һәм кече предприятиеләр мисалында яшь эшкуарлар өчен хезмәтне саклау буенча семинарлар | 2016-2020 еллар | ЯССТБ МКУ, АХ һәм АТИ (килешү буенча), “ХМҮ” ДКУ (килешү буенча) | - | - | - | - | - | - |

| | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | оештыру һәм үткәрү | | | | | | | | |
| 3. | Авыл яшьләре арасында «Авылда социаль проектлаштыру " район конкурсын оештыру һәм үткәрү | ел саен | ЯССТБ МКУ, АХ һәм АТИ (килешү буенча), “ХМҮ” ДКУ (килешү буенча) | Социаль проектлаштыруга укыган авыл яшьләренең чагыштырма саны авыл яшьләренең гомуми санына карата, % | -<br>15% | 30,0<br>17% | 30,0<br>19% | 30<br>22% | 30<br>24% |
| 4. | Район авыл яшьләре Форумын оештыру һәм үткәрү | ел саен | ЯССТБ МКУ, АХ һәм АТИ (килешү буенча), район җирлекләре БК (килешү буенча) | «Балык Бистәсе муниципаль районы аграр яшьләр берләшмәсе» район иҗтимагый оешмасы эшчәнлегенә җәлеп ителгән 15-30 яшьләрдәге яшьләрнең авыл яшьләренең гомуми санына карата чагыштырмача саны, % | 5,0<br>47,6% | 5,0<br>52,6% | 5,0<br>54,6% | 5,0<br>56,6% | 5,0<br>58,6% |
| 5. | Авыл яшьләрен иҗтимагый-сәяси активлыкны үстерү буенча эш технологияләренә өйрәтү | 2016-2020 еллар | “Мәгариф бүлеге” МКУ, БК, район җирлекләре БК (килешү буенча) | Җирле советларда авыл яшьләренең депутатларның гомуми санына карата | -<br>4,9% | -<br>6,9% | -<br>8,9% | -<br>10,9% | -<br>12,9% |

| | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 6. | Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы авыл яшьләренең электрон порталын булдыру | 2018 ел | БК | чагыштырма саны. % | | | | | |
| 7. | Авыл яшьләре арасында яшьләрне активлаштыру буенча күрсәтмә материаллар эшләү, әзерләү, тарату. | 2016-2020 еллар | ЯССТБ МКУ | | | | | | |
| 8. | Социаль программаларны гамәлгә кертү.<br>Социаль программаларны тормышка ашыру буенча семинарлар оештыру:<br>1. җәйге чорда балалар һәм яшүсмерләрнең сәламәт яшәү рәвешен формалаштыру «Күңелле ишек алды» ишегалды лагерьларын оештыру.<br>2."Авыл кичләре-Сельские вечера " яшьләр кичке лагерьларын оештыру | ел саен | ЯССТБ МКУ,<br>“Мәгариф бүлеге” МКУ,<br>“ХМҮ” ДКУ<br>(килешү буенча) | Авылны социаль үстерү программаларында катнашучы авыл яшьләренең чагыштырма саны авыл яшьләренең гомуми санына карата, % | -<br>56,2% | -<br>58,2% | -<br>60,4% | -<br>62,5% | -<br>64,5% |
| 9 | Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы авыл җирлекләрендә авыл туризмын үстерү буенча проектлар конкурсын уздыру | 2016-2020 еллар | ЯССТБ МКУ,<br>район җирлекләре БК (килешү буенча) | - | - | 15 | 20 | 25 | 30 |
| 10 | Авыл җирлекләрендә экологик бригада төзү | 2016-2020 еллар | ЯССТБ МКУ,<br>район җирлекләре БК (килешү буенча) | - | - | - | - | - | - |

| | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | | | | |
| **1 бүлек буенча барлыгы:** | | | | | 5,0 | 50,0 | 55,0 | 60,0 | 65,0 |

**2. Яшьләрнең социаль-икътисади проблемаларын хәл итү**

Әлеге бүлекнең максаты-авыл яшьләренең социаль-икътисади проблемаларын хәл итүгә юнәлдерелгән чаралар комплексын тормышка ашыру.

| № п\п | Чаралар исемлеге | Уздыру сроклары | Җаваплы башкаручылар | Ахыргы нәтиҗәләр не бәяләү индикатор лары, үлчәү берәмлеге | Финанс чыгымнары (агымдагы финанслау), мең сум һәм индикатор күрсәткечләре | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | 2016 ел | 2017 ел | 2018 ел | 2019 ел | 2020 ел |
| 1 | Авыл җирлегендә яшәүче яшь гаиләләрне һәм белгечләрне торак белән тәэмин итү | 2016-2020 еллар | БК, район җирлекләре БК (килешү буенча) | - | за счет средств федерального бюджета, бюджета Республики Татарстан | | | | |
| 2 | Вакантлы эш һәм эш урыннары ярминкәләрен оештыру юлы гражданнарга эшкә урнашуда ярдәм итү | 2016-2020 еллар | ЯССТБ МКУ, "ХМҮ" ДКУ (килешү буенча) | - | - | - | - | - | - |
| 3 | Яшьләрне эшкә урнаштыру һәм һөнәри юнәлеш бирү буенча мәгълүматлар базасын формалаштыру | 2016-2020 еллар | "ХМҮ" ДКУ (килешү буенча) | - | - | - | - | - | - |
| 4 | Яшүсмерләр һәм яшьләрнең мәшгульлеге проблемалары буенча укыту-методик семинарлар һәм конференцияләр үткәрү | 2016-2020 еллар | ЯССТБ МКУ, "Мәгариф бүлеге" МКУ, "ХМҮ" ДКУ (килешү буенча) | - | - | - | - | - | - |

| | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 5. | 16 яшьтән 30 яшькә кадәрге эшсез авыл җирлекләрендәге хезмәт базарында актуаль булган һөнәр һәм белгечлекләр буенча һөнәри укытуны оештыру | 2016-2020 еллар | “ХМҮ” ДКУ (килешү буенча), район җирлекләре БК (килешү буенча) | - | - | - | - | - | - |
| 6. | Төрле һөнәр ияләрен җәлеп итеп, мәктәпләрдә «һөнәрләр көне» үткәрү | каждое полугодие | “Мәгариф бүлеге” МКУ,“ХМҮ” ДКУ (килешү буенча) | - | - | - | - | - | - |
| 7. | Яшьләр өчен вакансияләр ярминкәләре үткәрү | ел саен | ЯССТБ МКУ, “Мәгариф бүлеге” МКУ, “ХМҮ” ДКУ (килешү буенча) | - | - | - | - | - | - |
| 8 | Яшь механизаторлар арасында һөнәри осталык буенча район конкурслары үткәрү | ел саен | АХ һәм АТИ (килешү буенча), Агротехник техникум (килешү буенча) | - | 10,0 | 10,0 | 10,0 | 10,0 | 10,0 |
| 9 | Машина белән сыер саву операторлары арасында һөнәри осталык конкурслары үткәрү | ел саен | АХ һәм АТИ (килешү буенча) | - | 10,0 | 10,0 | 10,0 | 10,0 | 10,0 |
| 10 | Игенчеләр арасында һөнәри осталык конкурслары үткәрү | ел саен | АХ һәм АТИ (килешү буенча) | - | 10,0 | 10,0 | 10,0 | 10,0 | 10,0 |
| **2 бүлек буенча барлыгы:** | | | | | 30,0 | 30,0 | 30,0 | 30,0 | 30,0 |

**3.Ирекләләр хәрәкәтен үстерү**

Волонтерлык эшчәнлегенең төп бурычы-авыр тормыш ситуациясенә юлыккан кешеләргә социаль ярдәм күрсәтү. Ирекләлек эшчәнлеге-башка кешеләр файдасына индивидуаль яки күмәк рәвештә эш итүче гражданнарның үз-үзләрен күрсәтү ысулы.

| № п\п | Чаралар исемлеге | Уздыру сроклары | Җаваплы башкаручылар | Ахыргы нәтиҗәләрне бәяләү индикатор-лары, үлчәү берәмлеге | Финанс чыгымнары (агымдагы финанслау), мең сум һәм индикатор күрсәткечләре | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | 2016 ел | 2017 ел | 2018 ел | 2019 ел | 2020 ел |
| 1 | 14 яшьтән 35 яшькә кадәр волонтер булырга теләүчеләрне махсус Интернет-сайтта теркәү | даими | ЯССТБ МКУ, “Мәгариф бүлеге” МКУ | - | - | - | - | - | - |
| 2 | Сайтта теркәлгән волонтерларга паспорт тапшыру | даими | ЯССТБ МКУ, “Мәгариф бүлеге” МКУ | - | - | - | - | - | - |
| 3 | “Иң яхшы волонтер отряды” конкурсы | ел саен | ЯССТБ МКУ, “Мәгариф бүлеге” МКУ | - | 10,0 | 10,0 | 10,0 | 10,0 | 10,0 |
| 4 | Авыл волонтерлары слеты | ел саен | ЯССТБ МКУ, “Мәгариф бүлеге” МКУ, район җирлекләре БК (килешү буенча) | - | 10,0 | 15,0 | 15,0 | 15,0 | 15,0 |
| 5 | Ялгыз пенсионерларга ярдәм күрсәтү буенча тимурчылар хәрәкәте | даими | ЯССТБ МКУ, “Мәгариф бүлеге” МКУ, район җирлекләре БК (килешү буенча) | - | - | - | - | - | - |
| **3 бүлек буенча барлыгы:** | | | | | 20,0 | 25,0 | 25,0 | 25,0 | 25,0 |

## 4. Гражданлылык һәм патриотизм үсеше

Әлеге бүлекнең максаты - гражданлылык һәм патриотизм тәрбияләү, үсеп килүче буын шәхесен формалаштыру һәм үстерү өчен кирәкле шартлар тудыру.

| № п\п | Чаралар исемлеге | Уздыру сроклары | Җаваплы башкаручылар | Ахыргы нәтиҗәләрне бәяләү индикатор-лары, үлчәү берәмлеге | Финанс чыгымнары (агымдагы финанслау), мең сум һәм индикатор күрсәткечләре | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | 2016 ел | 2017 ел | 2018 ел | 2019 ел | 2020 ел |
| 1 | Авыл яшьләре арасында милли мәдәниятләр фестивальләре һәм кичәләре үткәрү | ел саен | ЯССТБ МКУ, “СМӨБ” МКУ | - | - | 15,0 | 15,0 | 15,0 | 15,0 |
| 2 | Җиңү көнен бәйрәм итүгә багышланган чаралар үткәрү | ел саен (май) | ЯССТБ МКУ, “СМӨБ” МКУ,“Мәгариф бүлеге” МКУ | - | 50,0 | 50,0 | 50,0 | 50,0 | 50,0 |
| 3 | Авыл яшьләре арасында туризм буенча ярышлар | ел саен | ЯССТБ МКУ, “Мәгариф бүлеге” МКУ | - | - | 15,0 | 15,0 | 15,0 | 15,0 |
| 4 | "Чисталык ишегалдыннан башлана!» яшьләр акциясе | ел саен (апрель) | ЯССТБ МКУ , район җирлекләре БК (килешү буенча) | - | - | - | - | - | - |
| 5 | "Аҗаган" район хәрби-патриотик уены | ел саен | ЯССТБ МКУ, “Мәгариф бүлеге” МКУ, “СМӨБ” МКУ, «ФОРПОСТ» үзәге, хәрби комиссариат бүлеге (килешү | - | 15,0 | 15,0 | 15,0 | 15,0 | 15,0 |

| | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | (февраль) | буенча | | | | | | |
| 6 | Хәрби хезмәткә чакырылырга тиешле яшьләр арасында хәрби-спорт ярышлар оештыру һәм катнашу | ел саен (апрель, октябрь) | ЯССТБ МКУ, “Мәгариф бүлеге” МКУ, “СМӨБ” МКУ, «ФОРПОСТ» үзәге, Хәрби комиссариат бүлеге (килешү буенча | - | 25,0 | 25,0 | 25,0 | 25,0 | 25,0 |
| 7 | Хәтер һәм кайгы көненә багышланган " Кайгы кыңгыравы» акциясе | ел саен (июнь) | ЯССТБ МКУ, “Мәгариф бүлеге” МКУ, “СМӨБ” МКУ, район җирлекләре БК (килешү буенча) | - | 5,0 | 5,0 | 5,0 | 5,0 | 5,0 |
| 8 | Хәрби хезмәткә чакырылучыларның район көнен үткәрү | ел саен | ЯССТБ МКУ, “Мәгариф бүлеге” МКУ, “СМӨБ” МКУ, район җирлекләре БК (килешү буенча), Хәрби | - | 25,0 | 30,0 | 30,0 | 30,0 | 30,0 |

| | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | комиссариат бүлеге (килешү буенча) | | | | | | |
| **4 бүлек буенча барлыгы:** | | | | | 120,0 | 155,0 | 155,0 | 155,0 | 155,0 |

## 5. Рухи, физик һәм иҗади үсеш

Авыл яшьләренең рухи, физик һәм иҗади үсешенә ярдәм итү интеллектуаль-иҗади һәм физкультура-сәламәтләндерү чараларын оештыруны һәм үткәрүне, шулай ук яшүсмерләр һәм яшьләр арасында сәламәт яшәү рәвешен формалаштыруга ярдәм итүне күздә тота

| № п\п | Чаралар исемлеге | Уздыру сроклары | Җаваплы башкаручылар | Ахыргы нәтиҗәләрне бәяләү индикатор-лары, үлчәү берәмлеге | Финанс чыгымнары (агымдагы финанслау), мең сум һәм индикатор күрсәткечләре | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | 2016 ел | 2017 ел | 2018 ел | 2019 ел | 2020 ел |
| 1 | Алкоголь, тәмәке, наркотиклар куллануны кисәтү буенча чаралар үткәрү. Коррупциягә һәм экстремизмга каршы юнәлтелгән профилактик акцияләр оештыру һәм үткәрү | даими | ЯССТБ МКУ, “Мәгариф бүлеге” МКУ, “СМӨБ” “Балык Бистәсе ҮРБ” (килешү буенча) | Сәламәт яшәү рәвешен формалаштыру программаларында катнашучы авыл яшьләренең чагыштырма саны авыл яшьләренең гомуми санына карата, % | 150,0<br>61,5% | 150,0<br>68,5% | 150,0<br>70,5% | 150,0<br>72,5% | 150,0<br>74,5% |
| 2 | "Авыл яшьләре" спартакиадасында катнашу | ел саен | ЯССТБ МКУ | Физкультура-сәламәтләндерү чараларына җәлеп ителгән авыл | -<br>56,5% | -<br>60,3% | -<br>62,3% | -<br>64,3% | -<br>66,3% |

| | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | яшьләренең чагыштырма саны авыл яшьләренең гомуми санына карата, % | | | | | |
| 3 | "Үрнәк яшь гаилә " район конкурсын үткәрү | ел саен | ЯССТБ МКУ, ГХАТ бүлеге | Интеллектуаль-иҗади чараларга җәлеп ителгән авыл яшьләренең чагыштырма саны авыл яшьләренең гомуми санына карата, % | - 80,2% | - 85,4% | - 90,8% | - 92,3% | - 95,8% |
| 4 | Әни, әти һәм мин-спорт гаиләсе " спорт конкурсы үткәрү | ел саен | ЯССТБ МКУ, “Мәгариф бүлеге” МКУ | | 7,5 | 10,0 | 10,0 | 10,0 | 10,0 |
| 5 | Районның яшьләр җыелма командалары арасында спорт ярышлары уздыру | ел саен | ЯССТБ МКУ, “Мәгариф бүлеге” МКУ | | | | | | |
| 6 | "Созвездие-Йолдызлык " эстрада сәнгатенең ачык республика яшьләр фестивалендә катнашу | ел саен | ЯССТБ МКУ , “Мәгариф бүлеге” МКУ, “СМӨБ” МКУ | | 50,0 | 50,0 | 50,0 | 50,0 | 50,0 |
| 7 | "ВАТАН “халык иҗаты республика яшьләр фестиваль-конкурсында катнашу | ел саен | ЯССТБ МКУ, “Мәгариф бүлеге” МКУ, “СМӨБ” МКУ | | 175,0 | 185,0 | 185,0 | 185,0 | 185,0 |
| 8 | КВН хәрәкәте үстерү | даими | ЯССТБ МКУ , Агротехник техникум (килешү буенча) | | | | | | |
| 9 | "Балык Бистәсе көне " мәдәни-спорт бәйрәмен уздыру | ел саен | ЯССТБ МКУ, “Мәгариф бүлеге” МКУ, “СМӨБ” МКУ | | 5,0 | 6,0 | 6,0 | 6,0 | 6,0 |

| | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | 10,0<br><br>50,0 | 10,0<br><br>55,0 | 10,0<br><br>55,0 | 10,0<br><br>55,0 | 10,0<br><br>55,0 |
| **5 бүлек буенча барлыгы:** | | | | | 447,5 | 466,0 | 466,0 | 466,0 | 466,0 |

## 6. Мәгълүмати тәэмин итү

Авыл яшьләрен мәгълүмат белән тәэмин итү системасын булдыру авыл яшьләренә массакүләм мәгълүмат чаралары, мәгълүмат-полиграфия продукциясе аша, шулай ук IT-технологияләрне куллану юлы белән махсус җайлаштырылган мәгълүмат җиткерергә мөмкинлек бирәчәк.

| № п\п | Чаралар исемлеге | Уздыру сроклары | Җаваплы башкаручылар | Ахыргы нәтиҗәләрне бәяләү индикатор-лары, үлчәү берәмлеге | Финанс чыгымнары (агымдагы финанслау), мең сум һәм индикатор күрсәткечләре | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | 2016 ел | 2017 ел | 2018 ел | 2019 ел | 2020 ел |
| 1. | Мәгълүмат үзәген булдыру:<br><br>- яшьләр белән эшләү тәҗрибәсе белән уртаклашу буенча яшьләр берләшмәләре лидерлары катнашында презентацияләр, түгәрәк | 2016-2020 еллар | ЯССТБ МКУ, район җирлекләре БК (килешү буенча) | Авыл яшьләренең барлык консультация төрләре (шәхси, электрон, телефон) белән колачланган | - | - | - | - | - |

| | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | өстәлләр;<br><br>- яшүсмерләр һәм яшьләр белән эшләүне оештыру өчен мәгълүмати-методик кулланмалар эшләү һәм нәшер итү; | | | чагыштырма саны авыл яшьләренең гомуми санына карата, % | 48,7 % | 50,7% | 52,7% | 54,7% | 56,7% |
| 2 | Авыл җирлегендә яшьләр сәясәте өлкәсен гамәлгә ашыру тематикасы буенча методик кулланмалар булдыру | даими | ЯССТБ МКУ, “Мәгариф бүлеге” МКУ | | 5,0 | 5,0 | 5,0 | 5,0 | 5,0 |
| 3 | Авыл җирлекләрендә оештыру эшләрен үстерү проблемаларын яктырту | даими | район җирлекләре БК (килешү буенча), “Авыл офыклары” редакциясе (килешү буенча | | - | - | - | - | - |
| 4 | Мәгълүмати кырны сыйфатлы, социаль видео- һәм басма продукция белән баету | даими | ЯССТБ МКУ, “Мәгариф бүлеге” МКУ | | - | - | - | - | - |

| | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | | | | |
| 5 | Авыл яшьләре белән эшләү тәҗрибәсен өйрәнү һәм гомумиләштерү | даими | ЯССТБ МКУ “Мәгариф бүлеге” МКУ, район җирлекләре БК (килешү буенча) | - | - | - | - | - | - |
| 2 | Яшьләр тематикасы буенча мәгълүмати-методик һәм фәнни әдәбиятны сайлап алу һәм системалаштыру | даими | ЯССТБ МКУ, “Мәгариф бүлеге” МКУ, район җирлекләре БК (килешү буенча) | - | - | - | - | - | - |
| 3 | Авыл яшьләре белән эшләүне оештыру өчен мәгълүмати-методик кулланмалар эшләү һәм нәшер итү | даими | ЯССТБ МКУ, “Мәгариф бүлеге” МКУ, “Авыл офыклары” (“Сельские горизонты”) редакциясе (килешү буенча) | - | - | - | - | - | - |
| 4 | Район яшьләре өчен уку йортлары һәм социаль хезмәтләр турындагы мәгълүматлар белән мәгълүмати брошюралар һәм җыентыклар әзерләү | даими | ЯССТБ МКУ, “Мәгариф бүлеге” МКУ | - | - | - | - | - | - |
| 5 | "Авыл яшьләре" яшьләр сайтын булдыру | 2019 ел | ЯССТБ МКУ | - | - | - | - | - | - |
| **6 бүлек буенча барлыгы:** | | | | | 5,0 | 5,0 | 5,0 | 5,0 | 5,0 |
| **Программа буенча барлыгы:** | | | | | 627,5 | 686,0 | 686,0 | 686,0 | 686,0 |

*Кулланылган кыскартулар исемлеге:

БК - Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитеты;

ЯССТБ МКУ - Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының яшьләр сәясәте, спорт һәм туризм бүлеге”;

. “Мәгариф бүлеге” МКУ - “Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының мәгариф бүлеге” муниципаль казна учреждениесе;

“СМӨБ” МКУ- “Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының социаль- мәдәни өлкә бүлеге” муниципаль казна учреждениесе;

“ФОРПОСТ” үзәге МБУ – Балык Бистәсе муниципаль районының “ФОРПОСТ” җәмәгать тәртибен саклау буенча яшьләр (мәктәпләр) берләшмәләре үзәге” муниципаль бюджет учреждениесе.

ГХАТ бүлеге -Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитеты ГХАТ бүлеге;

“Балык Бистәсе ҮРБ” - “Балык Бистәсе үзәк район больницасы” дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесе;

“ХМҮ” ДКУ – “Балык Бистәсе районы халык мәшгульлеге үзәге” дәүләт казна учреждениесе;

ҖБ- җирле бюджет;

“Авыл офыклары” (“Сельские горизонты”) газетасы редакциясе- “Татмедиа” АҖ филиалы “Авыл офыклары” (“Сельские горизонты”) Балык Бистәсе муниципаль районы газетасы;

Район җирлекләре БК- Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы составына керә торган авыл җирлеге Башкарма комитетлары;

АХ һәм АТИ-Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының Балык Бистәсе муниципаль районы авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсе;

Агротехник техникум - Балык Бистәсе “Агротехника техникумы” ДАҺБУ;

Хәрби комиссариат бүлеге- Татарстан Республикасы Хәрби комиссариатының Балык Бистәсе районы буенча бүлеге.